КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 23 ноябрь г.Казань № 1256

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елда «Россия юристлары ассоциациясе» бөтенроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан төбәк бүлегенә устав эшчәнлеген гамәлгә ашыруга һәм хокукый агарту өлкәсендә чаралар үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 8 февраль, 96 нчы карары белән расланган 2022 елда «Россия юристлары ассоциациясе» бөтенроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан төбәк бүлегенә устав эшчәнлеген гамәлгә ашыруга һәм хокукый агарту өлкәсендә чаралар үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елда «Россия юристлары ассоциациясе» бөтенроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан төбәк бүлегенә устав эшчәнлеген гамәлгә ашыруга һәм хокукый агарту өлкәсендә чаралар үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 8 февраль, 96 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел,

18 июль, 690 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 2022 елда «Россия юристлары ассоциациясе» бөтенроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан төбәк бүлегенә устав эшчәнлеген гамәлгә ашыруга һәм хокукый агарту өлкәсендә чаралар үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә, 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«3. Субсидия турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталындагы «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин